**2021-2022 уку елында мәктәпкәчә тәрбия эшенә анализ.**

2021-2022 уку елында районда 12 балалар бакчасы һәм 1 башлангыч мәктәп-балалар бакчасы эшләде. Аларда 664 бала тәрбияләнде, бу райондагы барлык мәктәпкәчә яшьтәге балаларның 59.5%-ын тәшкил итә. Ул уртача республика күрсәткеченнән калыша (72,5%).

| 2019-2020 уку елы | 2020-2021 уку елы | 2021-2022 уку елы |
|---|---|---|
| 59,8% | 58,9% | 59,5% |

2022 елның августына район бакчаларында **72** бала чиратта тора, шуларның **21**-се 1 яшькә кадәр,**39**-ы 1яшьтән 2 яшькә кадәр,**10**-е 2яшьтән 3 яшькә кадәр, 4яшьтән 5 яшькә кадәрге балалар арасында чират юк. Иң күп чират Олы Әтнә балалар бакчасында, калган бакчаларда да чират күзәтелә.

Балалар бакчаларында белем һәм тәрбия бирүдә 13 мөдир һәм 48 тәрбияче катнашты. Җитәкче кадрлар 100% югары белемле. Педагогларның 40(79%) югары белемле. Педагогларның квалификацион категорияләренә күз салсак 1(2%) югары квалификацион категориягә ия, 31(69% )1 кв. категориягә ия.

Балалар бакчасында 2017-2018 уку елында түләү буенча 50% льготалар белән – 158 кеше, 100% льготалар белән –15 кеше файдаланды(льготниклар исемлегенә күп балалы гаиләләр, инвалид балалар һәм ата-аналары инвалид булган балалар керә).

Балалар бакчаларының төп бурычы булып балаларның сәламәтлеген саклау тора. Балаларның авырып калган көннәре район буенча уртача 0,7 көн тәшкил итә.

| № | **Балалар бакчалары** | **1 баланың уртача авырып калдырган көн саны** |
|---|---|---|
| 1. | Түбән Бәрәскә балалар бакчасы | 0,5 |
| 2. | Яңа Шашы балалар бакчасы | 0,8 |
| 3. | Күлле-Киме балалар бакчасы | 0,7 |
| 4. | Күңгәр балалар бакчасы | 0,7 |
| 5. | Күшәр балалар бакчасы | 0,8 |
| 6. | Дусым балалар бакчасы | 0,7 |
| 7. | Комыргуҗа балалар бакчасы | 0,9 |
| 8. | Кышлау башлангыч мәктәп – балалар бакчасы | 0,7 |
| 9. | Түбән Көек балалар бакчасы | 0,6 |
| 10. | Олы Әтнә балалар бакчасы | 1,4 |
| 11. | Күәм балалар бакчасы | 0,7 |

| | | |
|---|---|---|
| 12. | Олы Мәңгәр балалар бакчасы | 0,5 |
| 13. | Бәрәзә балалар бакчасы | 0,7 |

Таблицадан күренгәнчә, еш авырып калдыручы балалар аз.

Уку елы дәвамында балалар бакчаларында "Ел тәрбиячесе -2022", "Яшел ут – 2022" республика конкурсларының муниципаль этабы, "Тукай шигырьләре" район конкурсы уздырылды.

| № | ДОУ | "Ел тәрбиячесе – 2022" | "Яшел ут -2022" | "Тукай шигырьләре" |
|---|---|---|---|---|
| 1 | Олы Әтнә бакчасы | Катнашучы - Биккинина С.Д., Мухамедзянова Л.Т., Киямова Р.Н., Хадиева Г.М. Исхакова Ф.М., **Җиңүче** – Хадиева Г.М. | **Җиңүче –** Биккинина Савия Динартовна | Шакирова Л.Х. Гайфуллина Н.Н, Зарипова З.Х. |
| 2 | Түбән Көек бакчасы | Район этабы – 2 урын | сертификат | 1 урын(Шигапова Ф.) |
| 3 | Кышлау башлангыч мәктәбе - бакчасы | | | |
| 4 | Күәм бакчасы | | | Халитова Иркә 1 дәрәҗә диплом |
| 5 | Түбән Бәрәскә бакчасы | катнашучы | | 3 дәрәҗә лауреат Шарафиева А.Х. |
| 6 | Күшәр бакчасы | | | |
| 7 | Күңгәр бакчасы | Гарипова Фаила Агзамовна катнашучы | | Гарипова Фаила Агзамовна 1 дәрәҗә диплом |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| 8 | Олы Мәңгәр бакчасы | | Зарипова И.З.<br>сертификат | Хамидуллина Г.И.<br>3 дәрәҗә диплом |
| 9 | Күлле-Киме бакчасы | | | |
| 10 | Дусым бакчасы | | | Хисматуллин Искәндәр (тәрбияче – Ханафиева Л.З.)<br>1 дәрәҗә диплом |
| 11 | Яңа Шашы бакчасы | | | Маугизова Камиля Рафилевна<br>1 дәрәҗә диплом |
| 12 | Коморгужа бакчасы | | | |
| 13 | Бәрәзә бакчасы | катнашучы | | Гилазова Эльмира Рафхатовна<br>1 дәрәҗә лауреат |
| 14 | Ташчишмә бакчасы | катнашучы | | 1 дәрәҗә диплом<br>Усманов Р. Р.<br>Хөснетдинова А, А. |

Тәрбиячеләрнең профессиональ конкурсларында Олы Әтнә, Түбән Көек балалар бакчалары тәрбиячеләре уңышлы чыгыш ясадылар. Балалар өчен оештырылган “Мин кышны ясыйм” район конкурсында Олы Әтнә, Олы Мәңгәр, Түбән Көек, Дусым, Кышлау, Комыргужа бакчаларының призлы урыннары бар.